# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Күк-Тау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**10.11.2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 10 ноябрендә 14.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Күк-Тау авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

-Күк-Тау авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;

- Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);

- Күк-Тау авылы зиратының хуҗалык корылмасына электр үткәрү өчен инвентарь һәм материаллар сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 61 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 44 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 44 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл жирлегенең Күк-Тау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Күк-Тау авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

-Күк-Тау авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;

- Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);

- Күк-Тау авылы зиратының хуҗалык корылмасына электр үткәрү өчен инвентарь һәм материаллар сатып алу кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Петровский Завод авыл җирлегенең Күк-Тау мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы А. Б. Хөснетдинов